Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

14 май 2019 ел                                                                                    № 19

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районында һәм Әлмәт шәһәрендә халык алдында тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 8 Март ур., 16 адресы , 16:45:020110:39 кадастор номерлы җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылу, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

- участокның алгы чигеннән минималь чигенү-1,9 м;
- корылмаларның Ян чикләреннән минималь чигенүе-5,9 м, 9,15 м;
- участокның арткы чигеннән минималь чигенү – 16 м.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 24 маенда 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә бер ай.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4 Җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылу, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларга кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 24 маена кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы А.Р. Хайруллин